ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«16» май 2018 ел** **№ 450**

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «2018 елга халыкка күрсәтелә торган Арча муниципаль районы Коммуналь комплексы оешмаларының торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында»2017 елның 18 декабрендәге 1432 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 156 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Арча районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының «2018 елга халыкка күрсәтелә торган Арча муниципаль районы Коммуналь комплексы оешмаларының торак-коммуналь хезмәтләренә тарифлар турында»2017 елның 18 декабрендәге 1432 номерлы карарына:

- Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 18 декабрендәге 1432 номерлы карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

2. Әлеге карарны «Арча хәбәрләре» («Арский вестник»),газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Р.В.Хәбибуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Ә. Галимуллин

*Башкарма комитетның*
*«___»____________ 2018 № ___*
*карарына 1 нче кушымта*

**Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар, шулай ук күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынын (наем өчен түләү (алга таба – торак хезмәтләре) тоту өчен түләү күләмнәре**

| № | Түләү исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), I яртыеллык 2018ел | Хезмәт күрсәтү үлчәү берәмлеге өчен тариф II яртыеллык 2018ел |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,45 | 2,50 |
| 2. | Санитар карап тоту һәм санитар чистарту торак биналарны (ишегалды җыештыру) | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,20 | 3,30 |
| 3. | Йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 2,12 | 2,15 |
| 4. | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 3,20 | 3,36 |
| 5. | Дератизация | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,18 | 0,18 |
| 6. | Йорт эчендәге инженер җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау:<br>- санитар-техник челтәрләр;<br>- җылыту челтәрләре;<br>- электр белән тәэмин итү челтәрләре;<br>-газ белән тәэмин итү челтәрләре | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | <br>1,70<br>0,10<br>0,40<br>0,10 | <br>1,70<br>0,10<br>0,40<br>0,15 |
| 7. | Торак йортны карап тотуга салкын су | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м | 0,15 | 0,15 |
| 8. | Торак йортны карап тотуга | аена торак бинаның | 0,65 | 0,65 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | электр белән тәэмин итү | гомуми мәйданы кв. м | | |
| 9. | Домофоннарга техник хезмәт күрсәтү | аена фатир | - | 43,20 |

Башкарма комитетның
инфраструктура үсеше бүлеге ТКХ,
энергетика һәм элемтә буенча секторы мөдире И. А. Рәхимов